КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«06»06.2019г. № 41-п

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2016 елның 29 июнендәге 18-п номерлы боерыгы белән расланган «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында үрнәк нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 15 маендагы 395 номерлы карары нигезендә БОЕРЫК БИРӘМ:

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2016 елның 29 июнендәге 18-п номерлы боерыгы белән расланган («Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2017 елның 30 октябрендәге 50-п номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә::

«җәмгыятьтә коррупциячел тәртипкә түзеп торалмаучанлык формалаштыру.»;

5.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«5.12. Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый советы утырышында карала торган мәсьәләләр буенча кирәкле белешмәләр һәм бәяләмәләр бирү өчен Иҗтимагый совет утырышына башкарма органнар,

коммерциячел булмаган оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар, башка белгечләр һәм гражданнар чакырылырга мөмкин.».

Җитәкче А. Р. Зарипов